Хатыйп Миңнегулов —

Казан федераль университеты профессоры

## Татар Әбугалисинасы

(Ризаэддин Фәхреддин эшчәнлегенең аерым мәсьәләләре)[1]

Бу фаный дөньяга бик күпләгән сәләтле, талантлы затлар килеп киткән. Аларның бер өлеше үз чорында билгеле булып та, бераздан онытылган. Икенчеләре — моның киресе. Өченчеләре исә — болары чагыштырмача аз санлы — үзе исән вакытта да, аннан соңгы буыннар хәтерендә дә яшәвен дәвам итә, кешелекнең, милләтнең юлдашына, сердәшенә, остазына әверелә. Бөек Ризаэддин хәзрәт Фәхреддин (1859—1936), аның исеме, бай мирасы — вакыт кысалары белән чикләнмәгән әнә шундый күренешләрнең берсе. Аннан башка без хәзер милли-рухи, гыйльми-мәдәни тормышыбызны күз алдына да китерә алмыйбыз. Иҗтимагый-мәгърифәти мәйданга әле яңарак кына аяк баскан вакытында ук ул мәшһүр Акмулланың (1831—1895) «Хөрмәтле Ризаэддин — бу камил зат» дигән бәясенә лаек була. Бераздан аның эшчәнлеге башка бик күп күренекле шәхесләр тарафыннан югары бәяләнә. Тукай Р. Фәхреддиннең һәм әдәби, һәм гыйльми-дини эшчәнлеген уңай яктан телгә ала. «Әгәр,— ди шагыйрь,— Русиядә Коръән тәрҗемә ителергә кирәк булса, мөтәрҗемлеккә иң муафикъ кеше  Риза казый. Чөнки ул «Әсма», «Сәлимә» кеби китаплары белән куәи тәхририя (язу көчен, сәләтен. — *Х. М.*) вә хәтта шигъриясен күрсәткән вә гомумән ифадәсе («сөйләме». — *Х. М.*) ачык, язу тарызы садә (стиле җиңел. — *Х. М.*) вә гүзәл бер язучыдыр [1, т. 4, 324]. Г. Исхакый, үзенең мәрсияви эчтәлекле бер язмасында Р. Фәхреддинне «олуг милли хезмәтче», «милли йортыбызны корышучы, төзүче... мөһәндис  (инженер. *Х. М.*)», «төрк милләтенең мөхтәрәм мөҗаһиды (көрәшчесе. *Х. М.*)» дип саный. «Инкыйраз» әсәренең авторы фикеренчә, «аның кыйммәте безнең үткәннәребезне белер өчен генә

[1] «Р. Фәхреддин иҗатында инсани фикерләрнең эволюциясе» («Эволюция гуманистической мысли в творчестве Р. Фахреддина») темасына Әлмәттә уздырылачак Халыкара фәнни-гамәли конференциягә доклад (18—19 апрель 2013 ел).

түгел, киләчәгемездәге барачак юлымызны, кыйбламызны тәгъйин итәр (ачыклар. — *Х. М.*) өчен дә бик зарурдыр. Риза хәзрәт мәрхүмнең истикъляль (бәйсезлек, азатлык. — *Х. М.*) тарафдары булуы шәхсыиятене хөрмәтләндерә торган бер эш булса, аның шул сәяси истикъляле таяндыра торган мәдәни истикъялемез өчен гомерене сарыф итүе, милли мәдәниятемезне ныгыту, тазарту өчен илле ел бер уйдан эшләве шул истикъляльнең (азатлыкның. — *Х. М.*) яшәве өчен кирәкле зәминне (җирлекне. — *Х. М.*) хәзерләве һичбер язып бетермәслек бер милли хезмәтдер» [2, 2—6; 3, 154—158].

Ризаэддин хәзрәт — милләттәшләребез арасында гына түгел, төрки-мөселман дөньясында да билгеле зат. Аеруча аны Төркия галимнәре югары бәяли. Болар арасында Әхмәд Мидхәт, Фуат Күпрелезадә кебек абруйлы шәхесләр дә бар. Р. Фәхреддин татарның күп кенә зыялылары, урысның В. Бартольд, А. Самойлович кебек күренекле галимнәре белән аралашып тора. Алман шәрыкшенасы Бертольд Шпулер аны төрк-татар халкының «моңа чаклы сирәк булган мәгънәви бер рәһбәре (җитәкчесе. — *Х. М.*)», «бик зур сәяси-дини, фәнни хезмәт күрсәткән бер галиме» дип атый [4, 229]. Мәгълүм ки, Р. Фәхреддин 1926 елда хаҗ сәфәре кыла һәм Гарәбстанда I Бөтендөнья ислам конгрессында Рәчәй мөселманнарының җитәкчесе сыйфатында катнаша, президиумга сайлана, чыгыш ясый, Согыд Гарәбстаны короле тарафыннан кабул да ителә. Бу фактлар үзләре генә дә Ризаэддин хәзрәтнең халыкара күләмдә абруйлы зат булуын күрсәтеп торалар. Бу сәфәргә барганда Р. Фәхреддин Истанбул каласында татар мөһаҗирләре [Г. Исхакый, З. Вәлиди, С. Максуди белән очраша (10, 256). Бу очрашуны мөгаен, совет органнары аның «исенә» төшереп торганнардыр. 1931 елда Кодес шәһәрендә уздырылган мөселманнарның Икенче Бөтендөнья корылтаенда Идел-Урал вәкиле буларак Г. Исхакый катнаша].

Шәхеснең үсеше, нindилеге, бер яктан, аның табигатенә, нәсел-нәсәбенә, икенче тарафтан, иҗтимагый-тарихи шартларга бәйле. Ризаэддин Фәхреддин шактый укымышлы, зыялы нәселдән. Күренекле әдип Фатих Кәриминең әнисе аның бертуганы булу да күп нәрсә хакында сөйли.

Дәүләтчелеген җуйган, геноцид сәясәтенә дучар ителеп шактый миңгерәүләтелгән халкыбыз XVIII гасыр ахырларына таба әкренләп аягына баса башлый. Кавемдәшләренең белем-мәгърифәткә, иман-әхлакка омтылыш ихтыяҗы Габдерәхим Утыз Имәнине (1754—1834) төрле тармакларда гамәл кылуга этәрә. Мәгърифәтчелек хәрәкәте XIX йөздә тагын да киңрәк колач ала. Мәйданга Ш. Мәрҗани, К. Насыйри кебек күпкырлы шәхесләр чыга. Үз чиратында алар башка талантлы шәхесләрнең өлгерүенә дә уңай йогынты ясый. Болар арасында Ризаэддин хәзрәт, мөгаен, беренчелекне тотадыр. Ул, иҗтимагый, милли, рухи ихтыяҗларны тирәнтен тоеп, дин, әхлак, тарих, әдәбият, шәрыкшенаслык, журналистика, фәлсәфә, археография, текстология һәм кайбер башка тармакларда хезмәт куя, казый, мөфти, баш мөхәррир кебек югары вазыйфаларны башкара, аларның һәрберсендә үзенең тирән эзен калдыра. Р. Фәхреддин өчен гадәттән тыш җаваплылык, тырышлык, намуслылык, үз-үзенә таләпчәнлек хас. Мәдрәсә белеме өстенә ул мөстәкыйль рәвештә үзенең гыйлем-күнекмәләрен арттыра, эзләнү, тәнкыйди караш кебек сыйфатларны даими юлдашына әверелдерә.

Безнең әдәбиятта элек-электән «камил инсан» мотивы эшкәртелеп килгән. Ягъни кеше нинди булырга тиеш? Адәм баласы бу якты дөньяда ник яши? Төп җаваплар исә шундый: беркем дә җиһанга мәңгелеккә килмәгән, үлем — һәркемнең өлеше; шуңа күрә инсан үзенә бирелгән гомерне мәгънәле итеп уздырырга бурычлы; моның өчен аның белемле, әхлаклы, иманлы булуы, үзгәләргә бары яхшылык кына кылуы, буыннар хәтеренә «игү ат» белән генә кереп калырлык итеп яшәве шарт. Ризаэддин хәзрәтнең шәхесе һәм эшчәнлеге нәкъ әнә шул «камил инсан» таләпләренә җавап бирерлек. Ул — остазлары Ш. Мәрҗани, К. Насыйри кебек олуг мөгаллим. Ә инде белем-тәрбия процессында остазның өлге, үрнәк булуы бик тә мөһим.

Р. Фәхреддин гасырлар буе тупланган, тормышта күп мәртәбәләр инанган һәм үз шәхесендә дә шәкелләшкән күркәм дини-әхлакый һәм инсани сыйфатларны үз укучыларына һәм тыңлаучыларына да җиткерергә тырыша. Аның «Нәсыйхәт», «Тәрбияле ана», «Тәрбияле бала» һәм шул төрдәге башка

китаплары адресатының аныклыгы, вәгазь-киңәшләренең тормышчанлыгы һәм үтемлелеге белән чын мәгънәсендә педагогик әсбап кебек. Ә инде олуг остазның «Җәвамигуль кәлим шәрхе» хезмәте адәм балаларын тәрбияләүнең тиңсез бер дәреслеге рәвешендә кабул ителә. Мөхәммәд пәйгамбәрнең 344 хәдисен шәрехләүгә корылган бу китапта яшәеш-тереклекнең бик күп төрле мәсьәләләре яктыртылыш таба. Аның өчен фикри тирәнлек, комплекслылык, тел-стильнең үтемлелеге хас.

Ризаэддин хәзрәт тәрбияви процесста аеруча хатын-кызның зур роль уйнавына игътибар итә. Аның фикеренчә, милләтнең киләчәге, ниндилеге турыдан-туры хатын-кызларның тәрбияле, белемле, әхлаклы булуына, аларның ана буларак үз вазыйфаларын ничек үтәүләренә бәйле. Мәгълүм ки, Р. Фәхреддинны язучы буларак таныткан күләмле ике әсәре бар: «Сәлимә, яки Гыйффәт» (1899), «Әсма, яки Гамәл вә җәзи» (1903). Бу язмаларның исемендә һәм үзәгендә хатын-кызлар тору тирән символик мәгънәгә ия. Сәлимә, Әсма образлары аркылы автор хатын-кызларга үзенең ихтирам-хөрмәтен, сөю-мәхәббәт, гаилә кору, намус-гыйффәтлелек турында карашларын шактый калку итеп гәүдәләндерә.

Әйткәнебезчә, Р. Фәхреддин — тырышлыкның, хезмәт сөючәнлекнең матур бер үрнәге. Бу төр сыйфатларга ул үз хезмәтләрендә дә еш басым ясый. Пәйгамбәр хәдисләрен шәрехләү барышында бөек мәгърифәтче болай ди: «Дөньяда иң ләззәтле икмәк адәм баласының үз кәсебе вә кул көче берлә табылган, маңгай тирләре агызу сәбәпле кулга кергән икмәк булыр...» «Алтын арыслан авызында, аны алыр өчен күп тырышу кирәк» [5, 82—83]. «Асар»ның беренче җилденә (1900) язган кереш сүзендә автор, элекке һәм хәзерге мөселманнарны чагыштырып, мондый фикерләрне әйтә: «Әүвәлге мөселманнар иртәгә дә яшәячәк кеше мисалында ахирәт өчен вә мең ел торачак кебек дөнья өчен тырышкан да булсалар, бу замана мөселманнары ялкаулык һәм ваемсызлык йокысына шулкадәр чумганнар ки, уяну ихтималы да бик ерак калган» [6, 25].

Р. Фәхреддин карашларында гыйлем-мәгърифәт гаять мөһим урынны

били. Үз эшчәнлегенең асыл максатын ул «милләтебезне укытуда һәм гыйлем» өйрәтүдә күрә [6, 21]. Аның фикеренчә, «гыйлемнән башка байлык, байлыктан башка гыйлем булмас. Ягъни гыйлемсез милләт баемас вә алга китмәс, баемаган милләт гыйлем өйрәнә алмас» [6, 23]. Фикерсез, надан миллионнарның эшен зиһенле, фикерле бер кеше хәл итә. Халык саны белән түгел, ә белемле, тәрбияле булуы белән көчле.

Р. Фәхреддиннең бер язмасында мондый юллар бар: «Әдип вә галимнәре булмаган халык бәхетсез, мәшһүр кешеләрен оныткан халык сакланмас; әдәбияты булмаган халык рухсыз» [6, 18]. Икенче бер урында ул «әдәбияттан мәхрүм халык — телсез вә милли тарихы булмаган халык — җирсездер», — дип тә куя [7, 3]. Ризаэддин хәзрәтнең әдәби иҗаты һәм әдәбият фәне өлкәсендәге эшчәнлеге хакында инде безнең берничә мәртәбә сөйләгәнебез һәм язганыбыз бар [8, 108—129; 9, 123—131; 9а, 62—68]. Шуңа күрә биредә ул мәсьәләгә махсус тукталмыйбыз, бары шунысын гына искәртәбез: Ризаэддин хәзрәт язмалары, элеккеге традицияләрнең дәвамы рәвешендә, синкретик характерда, ягъни аларда әдәби, гыйльми, дини, әхлакый, әдәби-тәнкыйди башлангычлар еш кына табигый төстә үрелеп бара. Мәсәлән, «Сәлимә» әсәрендә төп сюжет сызыгына бәйле рәвештә «Казан», «Идел», «Болгар», «төрки кавемнәр», «шигыйлар» һ. б.лар хакында тарихи-географик мәгълүматлар бирелә. «Асар»ның кереш мәкаләсендә, «гыйлем»; «галим» төшенчәләре хакында сүз барганда, автор әдәби сөйләмгә хас булган сурәтләрне куллана: «Фән юлында җиләк кебек газиз гомерләр, юкә балыннан татлырак вакытлар вә иң ләззәтле йокылар, мең төрле рәхәт чак һәм теләкләр фида вә корбан ителәләр. Бу дәрәҗәдә булган нәфесне тыюлар вә рәхмәтләр соңында теләгән гыйлеменнән өлеш алса, ул зур бәхет санала. Шул дәрәҗәдә ки, өстендә гади чикмән булган хәлдә, дөнья байлыгына күзе төшмәс, үзенең хәленә монасыйб бирелгән доктор, профессор, хәким, фәйләсүф, бөек галим исемнәрен алыштырырга риза булмас» [6, 22]. Әдип аңлавынча, «әхлак берлә әдәбият бергә булыр. Бер кавемнең әдәбияты нинди рәвештә булса, әхлагы да шул рәвештә булыр»[10, 105].

Р. Фәхреддин, төрле чыганакларга таянып, Чыңгыз хан, Туктамыш, Олуг Мөхәммәд, Сафагәрәй, Сөембикә һәм төрки-татарларның кайбер башка хөкемдарлары хакында махсус фәнни очерклар яза, аларның тормышы һәм эшчәнлеге аркылы халкыбыз тарихының мөһим сәхифәләрен яктырта. Милләтебезнең этник составы, үткән юлы хакында да аның бик тә эчтәлекле язмалары бар [11].

Ризаэддин хәзрәт тарихи шәхесләр, вакыйгалар турында сүз алып барганда, мөмкин кадәр объектив булырга омтыла: күптөрле факт-мәгълүматларга, чыганакларга таяна, куелган мәсьәләне тарихи контекстта, төрле яклап, төрле бәйләнешләрдә карый. Урыны белән үзенең шәхси мөнәсәбәтен дә белдереп куя. Мәсәлән, «Идегәй мирза» язмасында бу затның тарихи эшчәнлеген яктырта да, ахырда мондый сүзләрне әйтә: «Аллаһы Тәгалә гафу итсен, Идегәй мирза шәхси мәнфәгате өчен гомуми мәнфәгатьне корбан итте, Тимерләнгне бу мәмләкәткә алып килеп, Дәште-Кыпчак хөкүмәтен харап иттерде, һичвакыт җыелмас рәвештә мөселманнарның җәмгыятьләрен тараттырды, араларында булган мөнәсәбәтләрне өздерде. Хәзерге көндә бу җир мөселманнарының түбән һәм хур булып калуларының бер сәбәпчесе Тимерләнг булса, аның мондый һәлакәтне җиренә җиткерүче икенче сәбәпчесе Идегәй мирза булды» [10, 156].

Р. Фәхреддиннең тарихи-мәдәни хезмәтләре арасында күптомлык «Асар» китаплары аеруча кыйммәтле. Бу биобиблиографик хезмәтнең 8 җөзэдән (кисәктән) торган тәүге томы 1900—1904 елларда Казанда һәм Оренбургта дөнья күрә. Җиде кисәктән гыйбарәт булган икенче җилде 1904—1909 елларда Оренбургта нәшер ителә [6; 7]. Беренче том 1843 елда вафат булган кешеләр белән тәмамлана. Ә инде икенче җилд 1843—1874 еллар арасында үлгән адәм балаларын үз эченә ала. Ике томда барлыгы 465 кешенең тормышы һәм эшчәнлеге яктыртыла. 1910 елда зур өлеше төгәлләнгән өченче һәм дүртенче җилдләр аерым сәбәпләр аркасында, нигездә, басылмый кала. 1874 елдан алып вафат булган 260 тарихи шәхеснең (соңгысы — Ш. Мәрҗани) тәрҗемәи хәлен яктырткан III—IV томнар татар

һәм урыс телләрендә 2010 елда дөнья күрде [7]. Гомумән, җиде йөздән артык татар зыялысы (имамнары, әдип-галимнәре, мөгаллимнәре...) хакында мәгълүматлар биргән бу «Асар» томнары бәяләп бетергесез хәзинә. Алар халкыбызның тарихын, мәдәниятен, мәгарифен, рухи тормышын, кайгы-шатлыкларын, дөнья белән бәйләнешләрен, мәгыйшәттә тирән эз калдырган шәхесләрен тулы чагылдыра, буыннар арасындагы багланышларны, хәтер дәвамчанлыгын тәэмин итүгә, милли асылны саклауга гаять зур өлеш кертә. (Алар белән бергә ешрак очрашырга, андагы фикер-мәгълүматларны зиһенебезгә ныграк сеңдерергә кирәк!) Шөкер Ходайга, хәзер күптомлык «Татар энциклопедиясе» нәшер ителеп килә. Ә бит ул буш җирдә тумады. Аның нигезен, шактый өлешен Ш. Мәрҗаниләр, Ризаэддин хәзрәтләр төзегән биобиблиографик мәгълүматлар тәшкил итә.

1908—1917 елларда Оренбургта айга 2 мәртәбә «Шура» журналы нәшер ителә. Барлыгы — 240 сан. Бу иҗтимагый, әдәби-публицистик һәм мәгърифәти журналның баш мөхәррире — Р. Фәхреддин. Андагы күп материаллар да аныкы. Искиткеч бай эчтәлекле, энциклопедик характерлы бу журнал татарлар арасында гына түгел, башка төрки-мөселман кавемнәре даирәсендә дә киң таралыш таба; хәзер дә ул үткәнне өйрәнүдә ышанычлы чыганак буларак файдаланыла.

Р. Фәхреддин эшчәнлегенең янә бер мөһим тармагы — шәрыкшенаслык (ориенталистика, востоковедение). Гарәп, фарсы һәм төрки телләрен, әдәбиятларын, тарихын, фәлсәфәсен һәм гомумән рухи байлыгын камил белгән Ризаэддин хәзрәт өчен Шәрык чит-ят тараф түгел, ә үз ватаны кебек. Чынлыкта бит татар кавеме, аның рухи байлыклары да олуг Шәрыкның мөһим бер кыйсеме. Гарәп, фарсы, төрки дөньясы безне рухани яктан туендырган, әдәбиятыбызның үсешендә гаять зур роль уйнаган. Шуңа күрә Р. Фәхреддиннең шәркый мирас, аның олуг вәкилләре хакында язуы һич тә «роскошь» түгел, ә зарури, мантыйкый күренеш. Бөек остазыбызның Әл-Мәгарри (973—1057), Имам Газзали (1058—1111), Ибне Гарәби (1165—1240) Ибне Рөшдә (1126—1198), Ибне Таймия (1263—1328), Ибне Гарәбшаһ

(1388—1450), Әхмәд Мидхәд (1844—1913) кебек Шәрык классиклары турында язылган монографияләре факт-мәгълүматларга байлыгы, тирән эчтәлекләре, кызыклы күзәтү-фикерләре белән шәрыкшенаслык фәнендә гаять мөһим урынны били. Аларны тиешле аңлатмалар белән татар, урыс (инглиз) телләрендә бастыру бүгенге көннең күптән өлгергән мәсьәләләреннән берсе. (Ә моны башкарырлык галимнәребез бар!) Р. Фәхреддин «Шура» журналы битләрендә һәм Шәрык, һәм Гареб (шул исәптән урыс) классикларына да зур урын бирә: болар хакында мәкаләләр бастыра, аларның иҗатларыннан үрнәкләрне укучыларга тәкъдим итә. Шунысын да әйтик: «Шура» журналы күп кенә татар әдипләре өчен мөнбәр дә булып торган.

Гомумән, Р. Фәхреддиннең мирасы һәм эшчәнлеге шулкадәр зур һәм күпкырлы ки, хәтта алардагы төп моментларны атап китү дә мөмкин түгел. Өстәвенә бит әле ул күренекле дин һәм җәмәгать эшлеклесе, бик җаваплы урыннарда эшләгән җитәкче дә. Шунысы мөһим: ул һәммә эшен намус, гаделлек, үз тырышлыгы белән башкарган. Аңа патша дәверендә дә, совет чорында да төрле кыенлыкларны кичерергә туры килә. 1911 елның февраль аенда полиция һәм жандармерия төнге сәгать 1 дә аның Оренбургтагы фатирында тентү уздыра, бик күп язмаларын, китапларын алып китәләр. Бер елдан соң гына аларның бер өлеше кайтарыла, калганнары юкка чыга [7, 14]. Совет хакимияте урнашкач, дингә, аеруча исламга каршы кискен көрәш башлана: күпләгән мәчетләр ябыла, дин әһелләре сөрелә, юкка чыгарыла, гарәп хәрефле китапларның шактые яндырыла. Болар бар да мөфти, олуг галим, җәмәгать эшлеклесе Ризаэддин хәзрәтнең җанын телгәли. Күп еллар буе адәм балаларын юаткан, яшәргә дәртләндергән бу олуг зат вакыты белән үзе дә төшенкелеккә бирелә. 1929 елның 9 июнендә «Асар»ның «Сүз башы» өчен язылган текстта мондый юллар бар: « ... бу көндәге хәлне бәян итүгә мөмкинлегем юк... Газиз милләтем җан биреп ятканлыгы күз алдымда. Ни кайгы! Ни үкенеч! Ни хурлык һәм түбәнлек!... Өч йөз еллардан артык вакытлар вәхши урысларга, җәберләүче императорларга каршы торып

килгән, диннәрен һәм миллиятләрен, гореф һәм гадәтләрен саклауга батырлыклары вә дәртләре җиткән бу газиз кавем үз араларыннан җитешкән имансыз малайларга һәм һәртөрле исемнәр белән билгеле булган ерткычларга каршы җавап кайтарудан гаҗиз калдылар, шулай ук инкыйраз дәһшәтеннән үзләрен коткарырга көчләре җитмәде. Тыштан һөҗүм итүче дошманга күрә эчтән һөҗүм итүче дошман зарарлырак... Безнең максатлар тәмам җимерелде, кирпеч өстендә кирпеч калмады. Өмет тәмам өзелде...» [6, I том, 13—14]. Игътибар итегез: бу юлларда никадәр газап, никадәр фаҗига!.. Әйтерсең, аларны Ризаэддин хәзрәт түгел, башка кеше әйтә. Мөгаен, бу күңел төшенкелеге вакытлырак күренеш булгандыр. Советлар Берлегендә мөселманнарны, ислам динен эзәрлекләү, кысу дөнья җәмәгатьчелегендә, бигрәк тә мөселман илләрендә көчле ризасызлык уята. 1931 елда (1932 дә. — *Х. М.*) Кремль «СССРда ислам диненә иреклек, ислам диненә бер төрле кысу да юк» дигән кәгазьгә кул куйдыртып, бөтен дөньяга тарату өчен мөфти Ризаэддин Фәхреддинне Мәскәүгә чакыра. «Әмма ул мондый кәгазьгә кул куюдан баш тартып», «ялган сөйләү безнең динебездә юк» дип җавап бирә һәм Кремльнең динебезгә азатлык бирүен таләп итә» [К. Казанлы. Төрк-татар халкының бөек мөфтие Риза Фәхреддин//Азат Ватан (Мюнхен). — 1952. — № 1. — 12—16 б.] [4, 238]. Бу факт үзе генә дә кечкенә генә картның кыюлыгын, фидакарьлеген күрсәтеп тора. Ярымач торуына, төрле эзәрлекләү, кимсетүләргә дә карамастан, бу олуг зат башын ими, иман-ышанычына тугры кала. Ризаэддин хәзрәт үлгәч, дөнья матбугатында аны зурлап, олылап күп материаллар басыла. Ә совет матбугаты бу фактны телгә дә алмый, олуг шәхесне тәмам оныттырырга тели. Әмма барыбер халык, милләт Ризаэддин хәзрәтләрен хәтереннән чыгармый. Әкренлек, кыенлык белән булса да узган гасырның урталарыннан аның исеме, мирасы үз укучыларына кайтарыла башлый. Бу юнәлештә тәүге адымнарны Мөхәммәд ага Гайнуллин ясый. Бераздан бу эшкә зур галимебез Миркасыйм Госманов кереште. Аның Ризаэддин хәзрәт архивы, хезмәтләре турындагы язмалары зур вакыйга рәвешендә кабул ителде. Шунысы мөһим: ул бөек

мәгърифәтченең мирасын өйрәнү эшенә үзенең шәкертләрен дә тартты. М. Госманов җитәкчелегендә Р. Фәхреддин хакында 1999 елда, фәнни-библиографик җыентык дөнья күрде. «Рухият» нәшрияты 2006—2010 елларда «Асар»ның дүрт томын бастырып чыгарды. Бу гаять җитди, саваплы эшне башкаручыларга рәхмәттән, афәриннән башка сүз юк. Р. Фәхреддин мирасын өйрәнүгә һәм халыкка җиткерүдә Р. Әмирхан, Ә. Хәйри, Г. Хөсәенов, М. Рәхимкулова һәм башкалар да зур өлеш керттеләр. Олуг галимнең якташы, филология фәннәре кандидаты Р. Шаһиев та бу юнәлештә инде озак еллар буе нәтиҗәле генә эшләп килә. Аның 2005 елда дөнья күргән «Ризаэддин Фәхреддин: тормыш юлы һәм иҗат мирасы» дип исемләнгән дәреслек-хрестоматиясе [анда без фәкыйрегезнең дә «Ризаэддин Фәхретдин — әдип һәм әдәбиятчы» дигән мәкаләсе бар (219—220 б.)] инде менә берничә ел буе укучылар, студентлар һәм укытучылар тарафыннан бик теләп кулланыла. Соңгы елларда олуг галим эшчәнлегенә багышлап төрле чаралар еш булып тора. 2012 елның февраль ахырларында, мәсәлән, Әлмәт муниципаль институты җирлегендә зур конференция уздырылды. Аның эшендә Татарстанның көньяк-көнчыгыш районнары укытучылары, галимнәре, иҗат әһелләре катнашты. Ризаэддин хәзрәтнең туган авылындагы музей да нәтиҗәле эшли. Инде менә дистә еллап Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан «Ризаэддин Фәхреддин укулары» уздырылып килә. Аның үткән елгысы Зәй шәһәрендә оештырылган иде. Шунысы әһәмиятле: бу чараның материаллары аерым җыентык рәвешендә дә дөнья күрде. [12]. Китапта бу өлкәдәге бай тәҗрибә тупланган. 2013 елгы Республика күләм «Ризаэддин Фәхреддин укулары» (ул унынчысы иде) Кукмара бистәсендә үткәрелде. Анда бу олуг затның эшчәнлеген генә түгел, ә гомумән, элеккеге мирасны бүгенге рухи-әхлакый тәрбия бирү эшендә ничек, ни рәвешле файдалану хакында да җитди сөйләшү булды (Анда без фәкыйрегезгә дә катнашу һәм доклад сөйләү насыйп булды).

Кыскасы, Р. Фәхреддин эшчәнлеге, аның бай мирасы хәзергене элеккеге белән бәйли, бүгенгенең күп кенә сорау-ихтыяҗларына җавап бирә.

Бу олуг зат белән очрашу күңелләрне пакьли, зиһенне баета, әби-бабайларның рухы белән тоташтыра. Олуг мәгърифәтченең исем-атамаларындагы канәгатьләнүне, уңайлыкны, килештерүне, затлылыкны, нәфислекне, горурлыкны белдерүче «риза» һәм «фәхер» компонентлары да аның җисеменә туры килеп торалар. Ризаэддин хәзрәтнең мирасы инсаннарны ризалата, күңелләрен бизи, нурландыра.

Иран-таҗик халыкларының 980—1037 елларда яшәгән Ибне Сина (Әбугалисина) атлы бөек галиме (табибы), философы, шагыйре бар. Ул бөтендөнья күләмендә гыйлемлелекнең, зирәклекнең өлгесе итеп карала. Ф. Әмирхан Ризаэддин Фәхреддинне «энциклопедик белем иясе, XX йөз Әбугалисинасы» дип атый [12, 84]. Әдипнең бу сүзләрен бераз гына үзгәртеп Ризаэддин хәзрәтне «Татар Әбугалисинасы» дип тә атарга мөмкин. Ул бу исемгә, һичшиксез, лаеклы зат.

**Әдәбият**


1. Габдулла Тукай. Әсәрләр. Дүрт томда. IV том. — К.: Татар. кит. нәшр., 1977. —432 б.

2. Гаяз Исхакый. Мөфти Ризаэддин хәзрәт// Яңа милли юл. — 1936. — № 7—8. — 2—6 б.

3. Хатыйп Миңнегулов. Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты. — К.: Татар. кит. нәшр., 2004. — 368 б.

4. Хатыйп Миңнегулов. Чит илләрдәге татар әдәбияты. — К.: Мәгариф, 2007. — 400 б.

5. Ризаэддин бине Фәхреддин. Җәвамигуль-кәлим шәрхе/Басмага әзерләүчеләр: Мәдинә Рәхимкулова һәм Равил Үтәбай-Кәрими. — К.: Иман, 1995. — 607 б.

6. Ризаэддин Фәхреддин. Асар. I том/Фәнни мөхәррире — Миркасыйм Госманов, төзүчеләре — Раиф Мәрдәнов, Рамил Миңнуллин; русча текст — Сөләйман Рәхимов. — К.: Рухият, 2006. — 360 б.; II том, 2009. — 304 б.

7. Ризаэддин Фәхреддин. Асар. III—IV томнар / Фәнни мөхәррире Миркасыйм Госманов... — К.: Рухият, 2010. — 648 б.

8. Хатыйп Миңнегулов. Гасырлар өнен тыңлап. — К.: Мәгариф, 2003. — 335 б.

9. Хатип Миннегулов. О научно-просветительской деятельности Ризаэддина Фахреддина/Х. Миннегулов. Записи разных лет. — К.: Идел-Пресс, 2010. — С. 123—131.

9а. Хатыйп Миңнегулов. Гасырлар арасында уйланулар. — К.: Татар. кит. нәшр., 2010. — 320 б.

10. Ризаэддин Фәхреддин: тормыш юлы, иҗади мирасы: Дәреслек-хрестоматия/Төзүчесе — Р. Шаһиев. —К., 2005. — 272 б.

11. Ризаэддин Фәхреддин. Болгар вә Казан төрекләре/Басмага әзерләүче — Ә. Хәйруллин. — К.: Татар. кит. нәшр., 1993. — 287 б.

12. Белем һәм тәрбия бирү процессында Ризаэддин Фәхреддин мирасын өйрәнүнең заманчалыгы. VIII кисәк. — К., 2012. — 224 б.

18. 02. 2013